ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 август 2020ел № 3706

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 7 апрелендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 25 сентябрендәге 4863 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «таможня эше» сүзләрен «таможня җайга салуы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 пунктта:

- 2 пунктчада «шәһәр бюджетына түләүләр буенча түләнмәгән бурычлары өлешендә» сүзләрен «- шәһәр бюджетына түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктчаны өстәргә:

«2.1) индивидуаль эшмәкәр булмаган гражданны банкрот дип тану «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң шәһәр бюджетына түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә;»;

- 3 пунктчада «оешма милке җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан аларны түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле, шәһәр бюджетына түләнмәгән» сүзләрен «оешма мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан аларны түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле, шәһәр бюджетына түләнмәгән» сүзләренә алмаштырырга;

- 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) штраф рәвешендәге җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында яки гаепне кичерү турында актлар кулланганда яки суд тарафыннан шәһәр бюджеты керемнәре администраторының шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуга нигез булган карар кабул ителгәндә;»;

- 5 пунктчаның беренче абзацында «3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр» сүзләрен «3 һәм 4 пунктларында каралган нигез» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктчаны өстәргә:

«6) теркәүче орган карары буенча юридик зат бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан чыгарылганда һәм «Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 бүлекнең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкару производствасы тәмамлану турында элек чыгарылган карар булганда, – шәһәр бюджетына түләүләр буенча оешма мөлкәтенең җитәрлек булмавы һәм әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле түләнмәгән бурыч өлешендә. «Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, теркәүче органның юридик затны бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан чыгару турындагы карары гамәлдән чыгарылган дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә шәһәр бюджетына түләүләр буенча элек түләтүгә өметсез дип танылган бурыч бюджет (бухгалтерлык) исәбендә яңадан торгызылырга тиеш.»;

3) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза билгеләү турында карарны үтәү туктатылу турында карар чыгарылган булса, әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар түләтүгә өметсез дип танылa.»;

4) 5 пунктның 5 пунктчасында:

- бишенче абзацта «3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр» сүзләрен «3 һәм 4 пунктларында каралган нигез» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзацны өстәргә:

«- гражданны банкрот дип тану турында арбитраж суды карары.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов